| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.01.2025ел Олы Подберезье ав. № 86

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 213-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр проектын (1 нче кушымта) кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы карары буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә: төркем җитәкчесе -Емельянова Оксана Михайловна, төркем әгъзалары - Пыгина Юлия Владимировна, Фролова Ольга Васильевна.

4. Гавами тыңлауларны 2025 елның 28 февралендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Ирек мәйданы, 31 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Подберезье авылы мәдәният йорты бинасында уздырырга.

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге советы депутатларының һәм гражданнарның «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье

авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча килүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча
эшче төркемгә йөкләргә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең https://bpberez-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге
Башлыгы О.М.Емельянова

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге
Советының 2025 елның 27.01
86 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр**

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 5 статьясының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 23 пункт өстәргә:

«23) хуҗалык кенәгәләрендә «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы гражданнарны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

2. 11 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле референдум комиссиясе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга.

3. 12 статьяның 3 өлешендәге 3 абзацында «Җирлекнең яисә» сүзләрен «яисә» сүзенә алмаштырырга.

4. 13 статьяда:

- 5 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясен» сүзләрен «Сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;
- 8 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Сайлау комиссиясе тарарфыннан» сүзләренә алмаштырырга;
- 12 өлештә «Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

5. 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 7 депутаттан тора.».

6. 32 статьяның 1 өлешендә «Җирлек сайлау комиссиясе.» сүзләрен «Сайлау комиссиясе.» сүзләренә алмаштырырга.

7. 33 статьяда:

- 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 32 пункт өстәргә:

«32) Башкарма комитет формалаштыруда катнашу, шул исәптән Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларының, Башкарма комитетның тармак

(функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләренең урынбасарларын билгеләп кую яисә килештерү, шулай ук мондый катнашуның рәвешләре һәм тәртибе;»;

- 32 пунктны 33 пункт дип санарга;

1 өлешнең 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

8. 40 статьяда:

- 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) чит ил агенты статусы алуы;»;

13 пунктны 14 пункт дип санарга.

9. 43 статьяның 6 өлешендәге 2 пунктында:

«а» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппараты,» сүзләрен һәм «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. 45 статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында:

«а» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппараты,» сүзләрен һәм «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга.

11. 46 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18) чит ил агенты статусы алуы;».

12. 49 статьяда:

- 1 өлешнең 5 пунктында түбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:

хуҗалык кенәгәләрендә «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны исәпкә ала.».

13. 51 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге
Советының 2025 елның 27.01
86 номерлы
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм гражданнарның анық турында фикер алышуда катнашуына үзгәрешләр кертү хакында»карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советына 422335, Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Ирек мәйданы, 31 йорт адресы буенча кушымтада бирелгән үрнәк нигезендә язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы формасында кертелә:

| № № | Пункт, пунктча | Проект тексты | Проект тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, текст проекты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.А., адресы, телефоны, эш, уку урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр Олы Подберезье авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендында урнаштырылган көннән алып бер ай эчендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422335, ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье авылы, Ирек мәйданы, 31 йорт яисә почта аша (конвертка «Устав турында» яисә «гавами тыңлаулар» тамгасы куеп), шулай ук факс буенча 30-0-24.

Гаризалар эш көннәрендә гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм гавами тыңлаулар үткәрү буенча даими комиссиягә, җирле үзидарәгә карау өчен тапшырыла.